# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге составына керүче Түбән Яке торак пунктында 2021 елга үзара салым кертү турында

№3 «13» ноябрь, 2020 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлегенең Түбән Яке торак пунктында узган гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге Түбән Яке торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2021 елда 400 (дүртйөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- Түбән Яке авылында, Октябрь урамына вак таш җәю ( сатып алу, ташу, килешү буенча түләү).
- Түбән Яке торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.

- Түбән Яке торак пунктында урам утлары, яктырткычлар, махсус җиһазлар урнаштыру (сатып алу, килешү буенча түләү).

3. Әлеге карарны Яке авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Яке авыл җирлеге Башлыгы урынбасары Ф.Г.Насибуллин